СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.09.2022 г.Зеленодольск № 94

Зеленодольск шәһәре Советының 2019 елның 26 декабрендәге 276 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Зеленодольск муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» МБУ җитәкчесе П. Н. Сергеевның Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре Советы **карар кылды:**

1. 1. Зеленодольск шәһәре Советының 2019 елның 26 декабрендәге 276 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

25 статьяның 3 пунктындагы 3.1 пунктчасын ЖЗ – рөхсәт ителгән куллануның төп төрләренең урта катлы күпфатирлы торак төзелеше зонасы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| **Рөхсәт ителгән кулланy төренең коды** | **Рөхсәт ителгән куллану төренең аталышы** | **Җир кишәрлекләренең чик күләмнәре һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрлары** | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | **җир кишәрлегенең күләме** | **корылма катларының иң чик саны һәм иң чик биеклеге** | **төзелешнең максималь проценты** | **җир кишәрлекләре чикләреннән минималь чигенү** |
| **Рөхсәт ителгән куллануның төп төрләре** | | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 2.1.1 | Аз катлы күп фатирлы торак төзелеше | минималь - 400 кв. м.; максималь- билгеләнми. | Төп корылма катларының иң чик саны – 4 (мансардны да кертеп ); Төп корылманың иң чик биеклеге- 15 м; Киртәнең максималь биеклеге-1 м. | 40 % | 5 м. Барлыкка килгән төзелеш шартларында чигенү яисә кызыл линия буенча бина, төзелеш һәм корылмаларның урнашуы рөхсәт ителә. |
| 2.5 | Урта катлы торак төзелеше | билгеләнми | Төп корылма катларының иң чик саны – 9 (мансардны да кертеп ); Төп корылманың иң чик биеклеге- билгеләнми; Киртәнең максималь биеклеге-1 м. | 40 % | 5 м. Барлыкка килгән төзелеш шартларында чигенү яисә кызыл линия буенча бина, төзелеш һәм корылмаларның урнашуы рөхсәт ителә. |
| 3.5.1 | Мәктәпкәчә, башлангыч һәм урта гомуми белем | билгеләнми | билгеләнми | 80 % | 5 м. Барлыкка килгән төзелеш шартларында чигенү яисә кызыл линия буенча бина, төзелеш һәм корылмаларның урнашуы рөхсәт ителә. |

25 статьяның 14 пунктының 14.1 пунктчасында – Р1-Шартлы рөхсәт ителгән куллануның рөхсәт ителгән төрләренең сәнәгать производствосы объектлары зонасы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| **Рөхсәт ителгән куллану төренең коды** | **Рөхсәт ителгән куллану төренең аталышы** | **Җир кишәрлекләренең чик күләмнәре һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрлары** | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | **җир кишәрлегенең күләме** | **корылма катларының иң чик саны һәм иң чик биеклеге** | **төзелешнең максималь проценты** | **җир кишәрлекләре чикләреннән минималь чигенү** |
| **Шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төрләре** | | | | | |
| 6.9 | Складлар | билгеләнми | билгеләнми | 60 % | билгеләнми |
| 4.1 | Эш идарәсе | билгеләнми | билгеләнми | 100 % | билгеләнми |
| 4.7 | Кунакханә буенча хезмәте | билгеләнми | билгеләнми | 100 % | билгеләнми |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | күрсәтү | | | | |
| 4.9 | Автотранспортка хезмәт күрсәтү | билгеләнми | билгеләнми | билгеләнми | билгеләнми |
| 8.3 | Эчке тәртипне тәэмин итү | билгеләнми | билгеләнми | 100 % | билгеләнми |
| 3.5.2 | Урта һәм югары һөнәри белем | билгеләнми | билгеләнми | 80 % | 5 м. Барлыкка килгән төзелеш шартларында чигенү яисә кызыл линия буенча бина, төзелеш һәм корылмаларның урнашуы рөхсәт ителә. |
| 2.1.1 | Аз катлы күп фатирлы торак төзелеше | минималь - 400 кв. м.; максималь- билгеләнми. | Төп корылма катларының иң чик саны – 4 (мансардны да кертеп ); Төп корылманың иң чик биеклеге-15 м; Киртәнең максималь биеклеге-1 м. | 40 % | 5 м. Барлыкка килгән төзелеш шартларында чигенү яисә кызыл линия буенча бина, төзелеш һәм корылмаларның урнашуы рөхсәт ителә. |

25 статьяның 18 пунктының 18.1 пунктчасында – Р1-Рөхсәт ителгән куллануның шартлы рөхсәт ителгән төрләренең табигать ландшафтлары зонасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| **Рөхсәт ителгән куллану төренең коды** | **Рөхсәт ителгән куллану төренең исеме *** | **Җир кишәрлекләренең чик күләмнәре һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрлары** | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | **җир кишәрлегенең күләме** | **корылма катларының иң чик саны һәм иң чик биеклеге** | **төзелешнең максималь проценты** | **җир кишәрлекләре чикләреннән минималь чигенү** |
| **Шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төрләре** | | | | | |
| 5.2 | Табигый-танып-белү туризмы | билгеләнми | билгеләнми | билгеләнми | билгеләнми |
| 11.3 | Гидротехник корылмалар | билгеләнми | билгеләнми | билгеләнми | билгеләнми |
| 13.1 | Яшелчәчелек алып бару | минималь- 600 кв. м.; максималь – 5000 кв. | билгеләнми | билгеләнми | билгеләнми |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | м. | | | |
| 13.2 | Бакчачылык алып бару | минималь - 400 кв. м.; максималь – 1000 кв. м. | Төп төзелештәге катларның иң чик саны - 3 (мансардны да кертеп), ярдәмче корылмалар - 1; Төп корылманың иң чик биеклеге – 10 м; өстәмә корылмаларның-3,5 м (яссы түбәле), 4,5 м (кыек түбәле, кайчы биеклеге). | 20 % | урам-юл челтәренә чыгучы җир кишәрлегенең яклары өчен - 3 м; җир кишәрлегенең башка яклары өчен билгеләнми. Барлыкка килгән төзелеш шартларында чигенү яисә кызыл линия буенча бина, төзелеш һәм корылмаларның урнашуы рөхсәт ителә. |

2. .Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск шәһәре Советының шәһәр төзелеше, торак сәясәте, төзекләндерү, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск шәһәре Хакиме,**
**Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**